РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20


**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«30» 10 2018 г. №756

Ютазы муниципаль районы гомуми
белем бирү оешмаларында
төп гомуми белем бирү программалары
буенча башлангыч, гомуми, төп гомуми,
урта гомуми белем бирү буенча
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең
Сыйфат стандартын раслау турында

«Россия Федерациясендә мәгариф турында» 2012 елның 29 декабрендәге 273-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгының 09.09.2014 елныц 5110/14 номерлы «гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатының модель стандартын раслау турында»гы боерыгы нигезендә карар бирәм:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының "Ютазы муниципаль районы гомуми белем бирү оешмаларында төп гомуми, урта гомуми белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты стандартын (алга таба - Сыйфат стандартын) расларга.

2. «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге» МКУга Ютазы муниципаль районының муниципаль гомуми белем бирү оешмаларына Сыйфат стандартын җиткерергә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге»МКУ начальнигына йөкләргә.

Башкарма комитет җитәкчесе С. П. Самонина

Г. М. Гыйлаҗева
2-71-00

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Башкарма комитеты
җитәкчесе карары белән
«РАСЛАНДЫ»
«____» ________20___ел № _____

Ютазы муниципаль районы гомуми
белем бирү оешмаларында
төп гомуми белем бирү программалары
буенча башлангыч гомуми, төп гомуми,
урта гомуми белем бирү буенча
муниципаль хезмәтләр күрсәтүнец
Сыйфат стандарты

**1. Мунициципаль хезмәт алучылар**

Төп белем бирү программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү буенча муниципаль хезмәт алучылар булып Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы территориясендә яшәүче медицина күрсәткечләре буенча ярамаган билгеләре булмаган 6,5 яшьтән алып 18 яшькә кадәрге балалар тора.

**2. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең хокукый нигезләре**

2.1 Муниципаль хезмәт түбәндәге законнар, норматив хокукый актлар, методик һәм инструктив документлар нигезендә күрсәтелә:

- БМО Генераль Ассамблеясе тарафыннан 1989 елныц 20 ноябрендә хупланган Бала хокуклары турында Конвенция;
- 1993 елның 12 декабрендә бөтенхалык тавышы белән кабул ителгән Россия Федерациясе Конституциясе;
- 1992 елның 7 февралендәге «Кулланучылар хокукларын яклау турында" 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы;
- 2012 елның 29 декабрендәге «Россия Федерациясендә мәгариф турында" 273-ФЗ номерлы Россия Федерациясе Федераль законы;
- 1995 елныц 24 ноябрендәге «Россия Федерациясендә инвалидларны соцциаль яклау турында"гы 181-ФЗ номерлы Федераль закон;
- 1998 елның 24 июлендәге «Россия Федерациясендә бала хокукларының төп гарантияләре турында"гы 124-ФЗ номерлы Федераль закон;
- 2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында"гы 131-ФЗ номерлы Федераль закон;
- 2005 елныц 1 июнендәге «Россия Федерациясе дәүләт теле турында" 53-ФЗ номерлы Федераль закон»;

- "2008 елның 22 июлендәге Янгын куркынычсызлыгы таләпләре турында техник регламент" 123-ФЗ номерлы Федераль закон;
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 25 апрелендәге 390 номерлы карары белән расланган Россия Федерациясендә Янгынга каршы режим кагыйдәләре;
- Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү Кагыйдәләрең раслау турында" 2013 елның 15 августындагы 706 номерлы карары;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2013 ел, 30 августындагы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында»гы №1015 боерыгы;
- Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 22.01.2014 елдагы «Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча белем алуга гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында»гы № 32 боерыгы;
- 12.13130.2009 Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы эшләре, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-каза нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының 25.03.2009 ел, №182 боерыгы белән расланган «Шартлау-янгын һәм янгын куркынычы буенча ббүлмәләрнең, биналарның һәм тышкы җайланмалар категориясен билгеләү» 12.13130.2009 Кагыйдәләр җыелмасы;
- Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә белем бирү шартларына һәм укытуны оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр" 2.4.2821-10 СанПиН раслау турында" 2010 елның 29 декабрендәге 189 номерлы карары;
- Россия Федерациясе баш дәүләт санитар табибының «Гомуми белем бирү учреждениеләрендә, башлангыч һәм урта һөнәри белем бирү учреждениеләрендә укучылар туклануын оештыруга санитар-эпидемиологик таләпләр"не 2.4.5.2409-08 СанПиН раслау турында» 23.07.2008 елдагы №45 карары;
- Татарстан Республикасы Конституциясе;
- Татарстан Республикасының «Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында" 1992 елның 8 июлендәге 1560-XII номерлы законы;
- 2013 елның 12 гыйнварындагы «Татарстан Республикасы дәүләт теле буларак татар телен куллану турында" 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;
- 2013 елның 22 июлендәге «Мәгариф турында"гы 68-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы;
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының гомуми белем бирү учреждениеләрен норматив буенча финанслауны кертү турында" 2007 ел, 17 декабрь, №721 карары;
- Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Фактта күрсәтелә торган дәүләт хезмәтләре сыйфатының Татарстан Республикасы Дәүләт хезмәтләре сыйфатының билгеләнгән

стандартларына туры килү-килмәвен бәяләү тәртибе турында"гы 2009 ел, 30 июнь, №446 нчы карары;

- Гомуми белем бирү оешмасы уставы;
- Мәгариф эшчәнлеген регламентлаштыручы гомуми белем бирү оешмасының локаль актлары;
- Хезмәт күрсәтү мәсьәләләре буенча башка норматив актлар, билгеләнгән кагыйдәләр һәм нормалар.

**3. Муниципаль хезмәт алу өчен мөһим булган документлар исемлеге**

| № т/б | Документлар исемлеге | Документ бирүне гамәлгә ашыра торган оешма | Документны биргән көннән башлап, аның гамәлдә булу срогы |
|---|---|---|---|
| Гомуми белем алу өчен | | | |
| 1. | Бала ата-анасының (законлы вәкиленең) шәхесен таныклаучы документ | Россия Федераль миграция хезмәтенең территориаль органнары һәм структур бүлекчәләре, яшәү урыны буенча граждан хәле актларын теркәү органнары | |
| 2. | Ата-ананың (законлы вәкилнең) гаризасы | - | |
| 3. | Баланың туу турында таныклыгының төп нөсхәсе, яки гариза бирүченең туганлыгын раслаучы документ, баланың яшәү урыны буенча яки беркетелгән территориядә тору урыны буенча теркәлүен раслаучы таныклык яки документ; | | |
| 4. | Чит ил гражданнары яисә гражданлыгы булмаган затлар булган балаларның ата-аналары (законлы вәкилләре) өстәмә | | |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | рәвештә мөрәҗәгать итүченең туганлыгын (яисә бала хокукларын тәкъдим итүнең законлы булуын) раслаучы документ һәм мөрәҗәгать итүченең Россия Федерациясендә булу хокукын раслаучы документ тапшыралар | | |
| Җайлаштырылган төп гомуми белем бирү программасы буенча укыту өчен өстәмә документлар | | | |
| 1. | Психологик-медик-педагогик комиссиясенең рекомендацияләре | Психологик-медик-педагогик комиссия | |
| Урта гомуми белем алу өчен өстәмә документлар | | | |
| 1. | Билгеләнгән үрнәктәге төп гомуми белем турында аттестат | Гомуми белем бирү оешмасы | |
| Өйдә уку өчен өстәмә докукментлар | | | |
| 1. | Ата-ананың (законлы вәкиленең) өйдә укытуны сорап язган гаризасы | | |
| 2. | Сәламәтлек торышы турында медицина тикшерүе нәтиҗәсе | Яшәү урыны буенча сәламәтлек саклауны оештыру | 3 ай |

**4. Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибенә һәм шартларына таләп**

4.1. Муниципаль хезмәт шәхес, җәмгыять, дәүләт мәнфәгатьләрендә укыту һәм тәрбияләү максатында күрсәтелә, сәламәтлек саклауны һәм шәхеснең төрле яклы үсеше өчен уңай шартлар тудыруны тәэмин итә, шул исәптән белем алуга һәм өстәмә белем алуга укучыларның ихтыяҗларын канәгатьләндерү мөмкинлекләрен дә тәэмин итә.

4.2. Конкрет муниципаль гомуми белем бирү оешмасында (алга таба - Оешма) белем бирүнең эчтәлеге эшләнә һәм раслана торган гомуми белем бирү оешмалары тарафыннан мөстәкыйль рәвештә гамәлгә ашырыла торган мәгариф программалары белән билгеләнә.

4.3. Гомуми белем бирү программасына уку планы, календарь уку графигы, уку предметларының эш программалары, курслар, дисциплиналар (модульләр), бәяләү һәм методик материаллар, шулай ук укучыларны, тәрбияләнүчеләрне (алга таба - укучылар) тәрбияләү һәм укытуны тәэмин итүче башка компонентлар керә.

Гомуми белем бирү программалары, шул исәптән адаптацияләнгән төп белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеге Оешма тарафыннан билгеләнә торган уку дәресләре расписаниесе нигезендә оештырыла.

Оешмада уку елы 1 сентябрьдә башлана һәм Оешманың уку планы нигезендә тәмамлана.

4.4. Оешманың эш режимы (биш көнлек яки алты көнлек уку атнасы, укучыларның мәктәптә булу вакыты) эчке тәртип кагыйдәләре, башка локаль актлар, гамәлдәге санитар-эпидемиологик кагыйдәләрне һәм нормативларны исәпкә алып, Оешма уставы белән билгеләнә.

4.5. Укучыларның төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерүләре мәҗбүри йомгаклау аттестаңиясе белән тәмамлана.

Төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча дәүләт йомгаклау аттестаңиясен уңышлы узган затларга, тиешле дәрәҗәдәге гомуми белем алуны раслаучы төп гомуми яки урта гомуми белем турындагы аттестат бирелә.

Йомгаклау аттестаңиясен уңышлы узган затларга үрнәкләрен Оешма мөстәкыйль билгели торган мәгариф һәм (яки) квалификаңия турында документлар бирелә.

Йомгаклау аттестациясе узмаган яки йомгаклау аттестациясендә канәгатьләнерлек булмаган нәтиҗәләр алган затларга, шулай ук төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программасының бер өлешен үзләштергән һәм (яки) Оешмадан чыгарылган затларга Оешма

тарафыннан үрнәк буенча билгеләнгән белешмә бирелә.

4.6. Оешмада укучыларга медицина хезмәте күрсәтүне Оешма һәм медицина оешмасы арасында килешү нигезендә сәламәтлек саклау оешмасының медицина персоналы тәэмин итә.

4.7. Оешмада укулар расписаниесе укучыларга тукланырга җитәрлек вакытны тәшкил иткән тәнәфесне күздә тотарга тиеш.

Туклануны оештыру Оешмага яки Оешма белән килешү буенча җәмәгать туклануы оешмасына йөкләнә. Оешмада укучыларны туклandыру өчен бина (ашханә) каралырга тиеш.

Укучылар өчен бер тапкыр кайнар ризык (иртәнге аш) оештырылырга тиеш. Ата-аналар теләге буенча аларга төшке аш та бирелергә мөмкин. Озайтылган көн төркеменә йөрүче балалар ике тапкыр кайнар ризык белән тәэмин ителә (иртәнге һәм төшке аш).

4.8. Укыту-тәрбия процессын оештыруның нәтиҗәлелеген тәэмин итү һәм гомуми белем бирү программаларын тулысынча гамәлгә ашыру максатларында аерым категория белем алучыларга муниципаль хезмәт күрсәтүнең түбәндәге үзенчәлекләре карала:

- сәламәтлекләре буенча Оешмага йөри алмаган укучылар өчен медицина оешмасы биргән нәтиҗә нигезендә өйдә укулар оештырыла;

- озак вакыт дәвалануга мохтаж һәм сәламәтлеге буенча оешмада укырга мөмкинлекләре булмаган укучылар өчен медицина оешмасында белем алу мөмкинлеге карала.

4.9. Шәхеснең ихтыяҗларын, мөмкинлекләрен исәпкә алып һәм педагогик хезмәткәр белән мәҗбүри дәресләр күләменә бәйле рәвештә, Оешмада укыту көндезге, көндезге-читтән торып укыту яки читтән торып укыту ысулы белән үткәрелә.

Гаиләдә белем алу формасында һәм үзлегеңнән белем алу формасында уку (белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы оешмалардан тыш) алга таба Оешмада арадаш һәм дәүләт йомгаклау аттестациясен узу хокукы белән гамәлгә ашырыла.

Төрле белем алу һәм уку формаларын аралаштыру рөхсәт ителә.

Белем бирүнең һәр дәрәҗәсе буенча төп белем бирү

программасы буенча белем алу формалары һәм укыту формалары тиешле федераль дәүләт белем бирү стандартлары белән билгеләнә.

**5. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең матди-техник тәэмин ителешенә таләп**

5.1. Оешмада белем бирү программаларын тормышка ашыру өчен кирәкле биналар, бүлмәләр (сыйныф бүлмәләре, ашханә, гардероб, спорт һәм актлар заллары, уку остаханәләре, медицина кабинеты, китапханә һәм башкалар) булырга тиеш.

5.2. Оешма участогы территориясендә ихаталар булырга һәм ул яшелләндерелергә тиеш; җир участогында укыту-тәҗрибә, физкультура-спорт, ял итү, хуҗалык зоналары булдыру таләп ителә.

5.3. Һәр укучы аның буена ярашлы эш урыны белән (парта яки өстәл артында, уен модульләре һәм башкалар өчен) тәэмин ителергә тиеш.

5.4. Уку бүлмәләренең билгеләнүенә карап, укучылар җиһазларының төрле төрләре файдаланылырга мөмкин: мәктәп парталары, укучылар өстәлләре (бер урынлы һәм ике урынлы), аудитор, сызым яки лаборатория өстәлләре белән комплектта урындыклар, конторкалар һәм башкалар. Урындыклар урынына табуреткалар яки эскәмияләр файдаланмый.

5.5. Төп һәм өстәмә бүлмәләрнең мәйданы күләме гамәлгә ашырыла торган белем бирү программаларына, бер тапкыр сыйдырышлылыгына, укыту процессының технологияләренә, инженер-техник җиһазларга, кирәкле җиһазлар белән тәэмин ителешенә бәйле рәвештә санитар һәм төзелеш нормалары һәм кагыйдәләр таләпләренә туры китереп кабул ителә.

5.6. Оешма яраклаштырылган бинада урнашкан булса кирәклке биналар һәм бүлмәләр булырга тиеш: уку сыйныфлары, туклануны оештыру өчен бүлмәләр, медицина билгеләнешендәге бүлмәләр, рекреация, административ-хуҗалык бүлмәләре, санузеллар, гардероб, спорт, актлар заллары, уку остаханәләре, китапханә (мәгълүмат

үзәге).

**6. Муниципаль хезмәт күрсәтү куркынычсызлыгына таләпләр**

6.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүче оешмалар законсалыкта билгеләнгән тәртиптә юридик зат буларак теркәлергә һәм белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыру өчен лицензиягә; дәүләт аккредитациясенә ия булырга тиеш.

6.2. Муниципаль хезмәт күрсәтүче Оешма биналарында балаларның тору, аларны тәрбияләү һәм укыту өчен түбәндәге санитар-эпидемиологик кагыйдәләр һәм нормативларга, янгынга каршы таләпләр нигезендә шартлар тудырылырга тиеш.

6.3. Оешма Россия Федерациясе законсалыгында билгеләнгән тәртиптә аның компетенциясенә кертелгән функцияләрне үтәмәгән яки тиешенчә үтәмәгән, уку планы нигезендә белем бирү программаларын тулы күләмдә гамәлгә ашырмаган өчен җавап тота, үз чыгарылыш сыйныф укучыларының белем бирү сыйфаты, шулай ук укучыларның, оешма хезмәткәрләренең гомере һәм сәламәтлеге өчен җавап тота. Укучылар, ата-аналар (законлы вәкилләр) хокукларының һәм ирекләренең белем алу турындагы законнарда каралган һәм белем алуга хокукны бозу яки законсыз чикләү, белем бирү эшчәнлеген оештыруга һәм гамәлгә ашыруга таләпләрне бозган өчен оешма һәм аның вазыйфаи затлары Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе Кодексы нигезендә административ җаваплылыкка тартыла.

**7. Кабул итүчеләр өчен муниципаль хезмәтнең һәркем алырлык булуын тәэмин иткән таләп**

7.1. Муниципаль хезмәт алучыларга аны уку елы дәвамында бирү гарантияләнә.

7.2. Закон белән җайга салынмаган өлешендә укучыларның һәм аларның ата-аналарының (законлы вәкилләренең) хокуклары һәм

бурычлары Оешманың уставы һәм локаль хокукый актлары белән билгеләнә.

7.3. Оешма, укырга керүчене һәм (яки) аның ата-аналарын (законлы вәкилләрен) үз уставлары, белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиясе, дәүләт аккредитациясе турында таныклык, белем бирү программалары һәм белем бирү эшчәнлеген оештыру һәм гамәлгә ашыруны регламентлаучы башка документлар, укучыларның хокуклары һәм бурычлары белән таныштырырга тиеш.

7.4. Оешманы комплектлау җирле үзидарә органының территорияне балаларның яшәү урыннарына якынлыгын исәпкә алучы Оешмага беркетү турындагы норматив акты нигезендә башкарыла.

7.5. Гражданнарны кабул итү тәртибе Россия Федерациясе Мәгариф һәм фән министрлыгының 2014 елның 22 гыйнварындагы "Башлангыч гомуми, төп гомуми һәм урта гомуми белем бирү программалары буенча укыту өчен гражданнарны кабул итү тәртибен раслау турында" №32 боерыгы белән җайга салына.

7.6. Муниципаль хезмәтләрдән файдалану процессы үз эченә ала:

- баланың ата-анасы (законлы вәкиле) муниципаль хезмәтләр күрсәтүче Оешмага гариза бирүен;
- баланы Оешмага кабул итүне.

Беркетелгән территориядә яшәүче гражданнар өчен оешманың беренче классына гаризалар кабул итү агымдагы елның 1 февраленнән дә соңга калмыйча башлана һәм 30 июненнән дә соңга калмыйча тәмамлана.

Оешмага кабул итү, Оешманың күрсәтмә акты белән документлар кабул ителгәннән соң, 7 эш көне эчендә рәсмиләштерелә.

Беркетелгән территориядә яшәмәүче балалар өчен беренче

сыйныфка гаризалар кабул итү агымдагы елның 1 июленнән буш урыннар тутырганчыга кадәр, әмма агымдагы елның 5 сентябреннән дә соңга калмыйча башлана.

Беркетелгән территориядә яшәүче барлык балаларны беренче сыйныфка кабул итүне законлаштырган Оешма 1 июльдән иртәрәк беркетелгән территориядә яшәүче балаларны кабул итә.

7.7. Муниципаль хезмәт күрсәтүне туктатып тору гариза бирү характерында була. Оешмада муниципаль хезмәт алучы өчен урын түбәндәге очракларда саклана:

- бала яки ата-аналар (законлы вәкилләр) авыру чорында;
- баланың санатор-курорт дәвалануы чорына;
- документлар белән расланган нигезле сәбәпләр аркасында бала Оешмага укырга йөрмәгән очракта.

**8. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең кадрлар белән тәэмин ителеш дәрәҗәсенә таләп**

8.1. Оешма, штат расписаниесе нигезендә квалификация характеристикалары таләпләренә җавап бирүче, квалификацияле белгечләр белән тәэмин ителергә тиеш.

Оешма хезмәткәрләре закончалыкта билгеләнгән тәртиптә квалификацияләрен күтәрәләр, аттестация, аккредитация узалар, сертификат алалар. Оешма персоналын комплектлау тәртибе аның Уставы белән регламентлана.

8.2. Оешма хезмәткәрләренә административ-идарә, педагогик, укыту-ярдәмче һәм хезмәт күрсәтүче персоналлар керә.

8.3. Оешмада педагогик эшчәнлек башкарырга урта һөнәри яки югары белемгә ия һәм квалификация таләпләренә җавап бирүче, квалификация белешмәләрендә һәм (яки) һөнәри стандартларда күрсәтелгән затларга рөхсәт ителә.

8.4. Педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнергә түбәндәге затларга рөхсәт ителми:

- законлы көченә кергән суд карары нигезендә педагогик эшчәнлек белән шөгыльләнү хокукыннан мәхрүм ителгән затларга;

- хөкем ителгән яки элек хөкем ителгән, җинаять эзәрлекләвенә дучар һәм элек дучар булган затларга (реабилитацияләнү сәбәпле, җинаятьтә гаепләнү туктатылган затлардан тыш) шәхес тормышына һәм сәламәтлегенә, ирегенә, намусына һәм дәрәҗәсенә, шәхеснең женси кагылгысызлыгына һәм женси ирекләренә, гаиләгә һәм балигъ булмаган балаларга, халыкның сәламәтлегенә һәм иҗтимагый әхлаклылыгына, конституцион строй һәм дәүләт иминлеге нигезләренә каршы җинаятьләр өчен җинаять эзәрлекләнү, шулай ук иҗтимагый куркынычсызлыкка каршы гамәл кылган өчен (психиатрия стационарына законсыз урнаштырудан тыш, яла ягу һәм мәсхәрәләүдән тыш) хөкем ителгән затларга;
- аңлы рәвештә кылынган авыр һәм аеруча авыр җинаятьләр өчен хөкем ителгән яки элек хөкем ителгән затлар;
- Федераль законда билгеләнгән тәртиптә эшкә яраксыз дип танылган затлар; сәламәтлек саклау өлкәсендә дәүләт сәясәтен эшләү һәм норматив-хокукый җайга салу функцияләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимиятнең федераль органы раслаган таблицада китерелгән Исемлектә күрсәтелгән авырулары булган затлар.

8.5. Әйләнә-тирәдәгеләр өчен куркыныч тудыручы авырулар Исемлеге

| № т/б | Авырулар исемлеге |
|---|---|
| 1. | Кеше иммунодефициты вирусы белән бәйле авыру (ВИЧ) |
| 2. | Буынтыкаяклылар аша күчкән вирус бизгәкләре һәм вируслы геморрагик бизгәкләр |
| 3. | Гельминтозлар |
| 4. | Гепатит В |
| 5. | Гепатит С |

| | |
|---|---|
| 6. | Дифтерия |
| 7. | Күбесенчә женси юл белән күчә торган инфекцияләр |
| 8. | Лепра |
| 9. | Малярия |
| 10. | Бетләү, акариаз һәм башка инфестацияләр |
| 11. | Сап һәм мелиодоз |
| 12. | Түләмә |
| 13. | Туберкулез |
| 14. | Ваба |
| 15. | Чума |
| 16. | Сифилис |

8.6. Оешма хезмәткәрләре уставны, эчке тәртип кагыйдәләрен үтәргә, үзләренә йөкләнгән функциональ бурычларны сыйфатлы башкарырга, һөнәри этиканы төгәл үтәргә бурычлы.

Тиешле квалификация һәм профессиональлек белән беррәттән, Оешманыц барлык хезмәткәрләре дә югары мораль сыйфатларга, җаваплылык хисенә ия булырга, хокукый, әхлакый һәм этик нормаларны үтәргә тиеш.

Оешма хезмәткәрләре укучыларның һәм белем бирү өлкәсендәге башка катнашучыларның намусын һәм абруен ихтирам итәргә тиеш.

8.7. Оешма хезмәткәрләренә өстәмә һөнәри белем бирү Рөссия Федерациясе законнары нигезендә өстәмә һөнәри белем бирү оешмаларында, югары белем бирү оешмаларында һәм башка оешмаларда уку һәм (яки) стажировка үтү юлы белән кимендә өч елга бер тапкыр уздырыла.

8.8. Оешманың һәр хезмәткәре шәхси медицина кенәгәсенә ия булырга тиеш, анда медицина тикшерүләре һәм лаборатор тикшеренүләр нәтиҗәләре, кичергән йөгышлы авырулар,

прививкалар турында мәгълүматлар, һөнәри гигиена әзерлеге һәм аттестация узу турында мәгълүматлар кертелә. Профилактик прививкалар турында мәгълүматлар булмаганда, Оешмага кергән хезмәткәрләр профилактик прививкаларның милли календаре нигезендә прививка ясатырга тиеш.

8.9. Оешма җитәкчесе санитар кагыйдәләрне оештыру һәм үтәү буенча җаваплы зат булып тора, шул исәптән түбәндәгеләрне тәэмин итә:

- Оешманың барлык хезмәткәрләре тарафыннан санитар кагыйдәләр таләпләрен үтәүләрен;

- санитар кагыйдәләрне үтәү өчен кирәкле шартлар тудыруны;

- җитештерү контролен һәм лаборатор контрольне оештыруны;

- сәламәтлек торышлары буенча рөхсәткә ия булган, һөнәри гигиена әзерлеген һәм аттестацияне узган затларны эшкә кабул итүне;

- һәр хезмәткәргә шәхси медицина кенәгәләре булуны;

- хезмәткәрләрнең вакытлы медицина тикшерүләрен вакытында узуларын;

- гигиеник белем бирү программасы буенча курс гигиеник әзерлеген һәм яңадан әзерлекне ике елга бер тапкырдан да ким оештырмауны;

- гамәлдәге законнар, санитар кагыйдәләр һәм гигиена нормативлары нигезендә хезмәткәрләрнең хезмәт шартларын;

- дезинфекция, дезинсекция һәм дератизация чараларын оештыруны;

- беренче медицина ярдәме күрсәтү өчен аптечкалар булуны һәм аларны үз вакытында тулыландырылуын;

- Оешманың технологик, суыткыч һәм башка җиһазларының төзек эшен.

**9. Муниципаль хезмәт күрсәтү барышында һәм аны алырга теләп мөрәҗәгать иткәндә, муниципаль хезмәт күрсәтүләрдән файдаланучыларны мәгълүмат белән тәэмин итүгә таләп**

9.1. Муниципаль хезмәт күрсәтү һәм мәгариф оешмасы турында мәгълүмат торышы "Кулланучылар хокукларын яклау турында" һәм "Россия Федерациясендә мәгариф турында"гы федераль законнар таләпләренә, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 10.07 2013 ел "Интернет" мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә мәгариф оешмасының рәсми сайтында урнаштыру кагыйдәләрен раслау һәм мәгариф оешмасы турында мәгълүматны яңарту турында"гы 582 нче Карары таләпләренә туры килергә тиеш.

9.2. Оешмалар эшчәнлеген, муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибен һәм кагыйдәләрен мәгълүмати яктан тәэмин итү Татарстан Республикасы халкы өчен алырлык (доступно) булырга тиеш.

9.3. Мәгълүмат хезмәтләр кабул итүчеләргә ачык һәм һәркемгә ачык мәгълүмат ресурслары, шул исәптән аны массакүләм мәгълүмат чараларында, мәгълүмати-телекоммуникация челтәрләрендә («Интернет» челтәрендә оешманың рәсми сайтында), мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән җиткерелергә тиеш.

9.4. Оешмалар ачыклыкны һәм түбәндәгеләрнең һәркем файдалана алырлык булуын тәэмин итә:

1) мәгълүматның:

- оештыру датасы, гамәлгә куючысы, гамәлгә куючылар турында, Оешманың һәм аның филиалларының урнашу урыны (булганда), эш режимы, графигы, контакт телефоннары һәм электрон почта адреслары турында;

- идарә органнары һәм аларның структуралары турында;

- гамәлгә ашырыла торган белем бирү программалары турында, тиешле белем бирү программасында каралган белем бирү предметларын, курсларын, дисциплиналарны (модульләрне) күрсәтеп;

- белем бирү программалары буенча укучылар саны турында;

- белем бирү телләре турында;

- федераль дәүләт белем бирү стандартлары турында, белем бирү стандартлары турында (алар булганда);

- Оешма җитәкчесе, аның урынбасарлары, филиал җитәкчеләре

турында (алар булганда);

- белем дәрәҗәсен, квалификациясен һәм эш тәҗрибәсен күрсәтеп, педагогик хезмәткәрләрнең персональ составы турында;

- белем бирү эшчәнлеген матди-техник тәэмин итү турында (шул исәптән, практик дәресләр үткәрү өчен җиһазландырылган уку кабинетлары, китапханәләр, спорт объектлары, укыту һәм тәрбия чаралары, укучыларның туклану һәм сәламәтлеген саклау шартлары турында, мәгълүмати системаларга һәм мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрләргә керү мөмкинлеге турында, укучылар файдалана ала торган электрон мәгариф ресурслар турында да);

- кабул итү өчен урыннар саны турында;

- укучыларга стипендияләр, социаль ярдәм чаралары бирү шартлары турында;

- тулай торак, интернат, тулай торакта, чит шәһәрләрдән килгән укучылар өчен интернатта торак урыннар саны, тулай торакта яшәү өчен түләү формалаштыру турында;

- финанс белән тәэмин итү бюджет ассигнованиеләре хисабына физик һәм (яки) юридик затлар акчалары исәбеннән мәгариф турындагы килешүләр буенча гамәлгә ашырыла торган белем бирү эшчәнлеге күләме турында;

- финанс һәм матди чаралар керүе һәм финанс елы нәтиҗәләре буенча аларны тоту турында;

- чыгарылыш сыйныф укучыларын эшкә урнаштыру турында;

2) күчермәләре булуын:

- уставның;

- белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыруга лицензиянең (кушымталар белән);

- дәүләт аккредитациясе турында таныклыкларның (кушымталар белән);

- финанс-хуҗалык эшчәнлеге планы яки бюджет сметасы;

- локаль норматив актларның, укучыларның эчке тәртип кагыйдәләренең, эчке хезмәт тәртибе кагыйдәләренең, күмәк килешү

кагыйдәләренең;

- үзләрен тикшерү нәтиҗәләре турында отчетның;

- түләүле белем бирү хезмәтләрен, шул исәптән түләүле белем бирү хезмәтләре күрсәтү турында килешү үрнәгенең, һәр белем бирү программасы буенча уку бәясен раслау турында документның;

- мәгариф өлкәсендә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыручы органнар күрсәтмәләре, мондый күрсәтмәләрнең үтәлеше турында хисаплар;

- Россия Федерациясе закончалыгына ярашлы бастырып чыгару мәҗбүри булган оешма һәм (яки) урнаштыру карары буенча урнаштырыла торган башка мәгълүматның.

9.5. Муниципаль хезмәт алучылар күрсәтелгән хезмәт турында аның сайланышын тәэмин иткән кирәкле һәм дөрес мәгълүмат бирүне таләп итәргә хокуклы.

9.6. Укучыларның ата-аналарына (законлы вәкилләренә) белем бирү процессының барышы һәм эчтәлеге белән танышу мөмкинлеге тәэмин ителергә тиеш.

**10. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге**

10.1. Муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр исемлеге:

1) Оешманы бетерү яки үзгәртеп кору;

2) Оешмада төп мәгариф программалары буенча башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтү Сыйфаты стандартын бозу;

3) әлеге Стандартның 3 бүлегендә күрсәтелгән документларның булмавы;

4) Баланы Оешмада укытуга комачаулаган баланың сәламәтлек торышы турында медицина оешмасы бәяләмәсе булу.

10.2. Оешма идарәсе органы карары буенча, дисциплинар хатаны берничә тапкыр кылган өчен, 273-ФЗ номерлы Федераль законның 49

ст. 8-9 өлеше нигезендә, 15 яшькә җиткән укучыны әлеге Оешмадан чыгарырга рөхсәт ителә.

Белем алучыны Оешмадан куып чыгару дисциплинар җәза һәм педагогик йогынты чаралары нәтиҗә бирмәсә һәм алга таба да Оешмада булу башка укучыларга тискәре йогынты ясаса, аларның һәм Оешма хезмәткәрләренең хокукларын бозса, шулай ук Оешманың нормаль эшләвенә комачауласа, кулланыла.

Төп гомуми белем алмаган укучыны укудан чыгару турындагы карар аның ата-аналары (законлы вәкилләре) фикерен һәм балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау буенча комиссия ризалыгы белән кабул ителә. Ятим балаларны һәм ата-ана (законлы вәкилләре) тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларны төшереп калдыру турындагы карар балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе һәм опека һәм попечительлек органы ризалыгы белән кабул ителә.

Оешма укучыны Оешмада укудан төшереп калдыру турында ата-аналарга (законлы вәкилләргә) һәм «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге" МКУга кичекмәстән хәбәр итәргә тиеш.

Укучыны оешмадан чыгару Оешма җитәкчесе боерыгы буенча гамәлгә ашырыла.

**11. Муниципаль хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен тасвирлау**

11.1. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе булып башлангыч гомуми, төп гомуми, урта гомуми белем бирү программаларын үзләштерү тора.

11.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү буенча Оешма эше укучыларның ихтыяҗларын тулысынча канәгатьләндерүгә, муниципаль хезмәт күрсәтүнең сыйфатын өзлексез күтәрүгә юнәлдерелергә тиеш.

11.3. Муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү түбәндәге юнәлешләр буенча үткәрелә:

- күрсәтелгән таләпләр нигезендә хезмәт күрсәтүнең тулылыгы;
- гомуми белем бирү өлкәсендә белем бирү программалары

таләпләренең әлеге программаларны тормышка ашыруның факттагы нәтиҗәләре белән чагыштыру ысулы белән бәяләнә торган хезмәт күрсәтүнең нәтиҗәлелеге, шулай ук гражданнар мөрәҗәгатьләрен һәм халыктан сораштыру юлы белән;

- өзлексез гомуми белем бирү өчен шартлар тудыру.

11.4. Хезмәт күрсәтү нәтиҗәсе таблицада күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтү сыйфаты критерийлары белән тасвирлана.

| Күрсәткеч исеме | Үлчәү берәмлеге | Исәпләү формуласы | Мәгълүмат чыганагы | Индикаторның чик әһәмияте | Авырлык коэффициенты |
|---|---|---|---|---|---|
| Классларның фактик һәм нармотив буенча тулылыгы нисбәте | процент | Тф/Тн *100, анда: Тф-фактик тулыланганлык; Нт-классларның норматив буенча тулылыгы | Мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 9 |
| Олимпиада, конкурслар, конференцияләр, фестивальләр, смотрлар, күргәзмәләр, конференцияләр һәм башка шундый дәрәҗәдәге чаралар | процент | ОП/ОЧ*100%, аларда: ОП-олимпиада, конкурслар, конференцияләр,фестивальләр, смотрлар, күргәзмәләр, конференцияләр һәм башка шундый чаралар призерлары – укучылар саны; ОЧ – Оешмада укучыларның гомуми саны | | 2 - 3 | 9 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| призерлары-укучылар саны | | | | | |
| Оешмада дәүләт йомгаклау аттестациясе нәтиҗәләре буенча белемнәрен раслаган укучылар саны; | процент | ЧУпз/ОЧ*100% ЧУпз – отчет чорында дәүләт (йомгаклау) аттестациясендә үз белемнәрен раслаган укучылар саны; Оешмада дәүләт йомгаклау аттестациясендә катнашучыларның гомуми саны | Мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 10 |
| Оешма буенча укучыларның белемнәре сыйфаты | процент | ЧУО/ОЧ*100%, монда: ЧУО – укучылар саны, “4” һәм “5” билгеләренә укучылар саны, ОЧ - оешмада укучыларның гомуми саны | Мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 80 | 7 |
| Оешма буенча укучыларның өлгереше | процент | ЧУбд/ОЧ*100%, монда: ЧУбд – Оешмада икелеләрсез укыган укучылар саны, Оешмада укучыларныц гомуми саны | Мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 8 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| Оешмада тормыш эшчәнлеге куркынычсызлыгын бозулар саны, белем бирү процессында катнашучыларның сәламәтлеген саклау | очраклар | Мәгариф процессында катнашучыларның хезмәтне саклау таләпләрен бозуга бәйле, Оешманың матди базасының, мәктәп яны территориясенең торышы канәгатьләнерлек булмавы сәбәпле, имгәнү очраклары саны | Мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 0 | 8 |
| Квалификацион категориягә яки биләгән вазифасына туры килүгә аттестация үткән Оешманың педагогик хезмәткәрләре өлеше | процент | РУпа/ОЧ*100 %,монда: РУ па – Оешманың аттестация узган хезмәткәрләре саны, ОЧ – Оешманың отчет елында аттестация үтәргә тиеш булган хезмәткәрләре саны | Аттестация нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 100 | 9 |
| Оешманың беренче һәм югары категориягә ия булган педагогик хезмәткәрләре өлеше | процент | РВК/ОЧ*100 %, монда: РВК – Оешманың югары һәм беренче квалификацион категориягә ия булган хезмәткәрләр | Мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 75 | 8 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | е саны | | | |
| Педагогик кадрлар белән тәэмин ителгәнлек | процент | (КП/ПС)*100 %, монда:КП – педагогик хезмәткәрләр саны, ПС - педагогик ставкалар саны | "Гомуми белем бирү программасын гамәлгә ашыручы учреждение турында мәгълүматлар" (Росстат 2009 елның 27 июлендәге 150 номерлы боерыгы белән расланган) №1 гомуми белем бирү мәктәбенең статистик күзәтү формасы | 100 | 6 |
| Хезмәтнең сыйфаты һәм аны һәркем алырлык булуы белән канәгать кулланучылар өлеше | процент | (Ок+Од)/2*Ообщ)*100 монда: - Ок – хезмәт күрсәтүдән канәгать булган сораштырылучылар саны; Од – хезмәт күрсәтүнең барысы да алырлык булуыннн канәгать сораштырылучылар саны; Ообщ – сораштырылган хезмәттән файдаланучыларның | Мониторинг нәтиҗәсе буенча билгеләнә | 90 | 8 |

| | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|
| | | гомуми саны | | | |
| Укучылар арасында хокук бозулар һәм җинаятьләр саны | берәмлек | Хокук бозулар саны | Мониторинг нәтиҗәләре буенча билгеләнә | 0 | 7 |
| Кулланучылар, башка кызыксынган затлар ягыннан учреждение эшчәнлегенә нигезле шикаятьләр саны | берәмлек | Абсолют күрсәткеч (белем бирү оешмасына карата шикаятьләр анализы нигезендә билгеләнә,аларны гражданнар (оешмалар) хатлары рәвешендә почта яисә электрон почта аша һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүматлар рәвешендә җибәрәләр | Оешмага карата гражданнардан (оешмалардан) хат рәвешендә почта яисә электрон почта аша кергән шикаятьләрне анализлау һәм алар буенча кабул ителгән чаралар турында мәгълүмат нигезендә | 1 - 2 | 9 |

## 12. Муниципаль хезмәт стандартының үтәлмәвенә шикаять бирү, теркәү һәм аны карау тәртибе

**12.1.** Дәүләт хезмәте күрсәтү барышында гамәлгә ашырылган (башкарылган) гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять бирү Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибенә ярашлы яисә суд тәртибендә башкарыла.

12.2. Мөрәҗәгать итүченең шикаятьләре судка кадәр (судтан тыш) тәртиптә телдән яисә язмача, шул исәптән «Татарстан Республикасында электрон белем бирү» мәгълүмат системасы, Оешмага муниципаль задание биргән Татарстан Республикасы муниципаль берәмлеге җирле үзидарә органының интернет-сайты аша да адресланырга мөмкин:

- хезмәт күрсәтүче Оешма җитәкчесенә;
- “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының мәгариф бүлеге” МКУ начальнигына;
- Оешма аның карамагында булган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органы җитәкчесенә.

12.3. Муниципаль органга, җирле үзидарә органына яисә вазыйфаи затка аларның компетенцияләре нигезендә кергән язмача мөрәҗәгать, ул теркәлгәннән соң, 30 көн эчендә карала.

Өстәмә тикшерүләр уздыру кирәк булган очракларда, орган җитәкчесе, вазыйфаи зат яисә вәкаләтле зат морәҗәгатьне карау вакытын 30 көннән дә артмаган вакытка озайта, морәҗәгать җибәргән гражданга карау срогын озайту турында хәбәр итә.

Язмача мөрәҗәгатьтә булырга тиеш:

физик зат тарафыннан мөрәҗәгать бирелгәндә - аның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы - булган очракта), юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта - аның исеме;

аның буенча җавап җибәрелергә тиеш булган почта адресы,

мөрәҗәгатьне яңадан адресацияләү турында уведомление;
язма мөрәҗәгать җибәрелә торган дәүләт органы исеме, яисә тиешле вазыйфаи затның фамилиясе, исеме, атасының исеме;
мөрәҗәгатьнең асылы;

физик зат мөрәҗәгать иткән очракта - физик затның шәхси имзасы, юридик зат мөрәҗәгать иткән очракта - җитәкче (җитәкче урынбасары) юридик зат имзасы;
дата.

Мөрәҗәгатькә мөрәҗәгатьтә бәян ителгән мәгълүматны раслый торган документларның күчермәләре беркетелергә мөмкин.

12.4. Суд карарыннан риза булмыйча шикаять бирелгән мөрәҗәгать җиде көн эчендә, судка шикаять бирү тәртибен аңлатып, мөрәҗәгать иткән гражданга кире кайтарыла.

12.5. Муниципаль органнарда, җирле үзидарә органнарында гражданнарны шәхси кабул итү аларның җитәкчеләре һәм вәкаләтле затлар тарафыннан үткәрелә. Кабул итү урыны турында мәгълүмат, шулай ук кабул итү өчен билгеләнгән көннәр һәм сәгатьләр турында мәгълүмат гражданнарга җиткерелә.

12.6. Әгәр мөрәҗәгатьтә куелган сорауларның асылы буенча җавап бирелә алмый икән, әмма алар алга таба хәл ителгән очракта, граждан янә тиешле дәүләт органына, җирле үзидарә органына яисә тиешле вазыйфаи затка мөрәҗәгать җибәрергә хокуклы.

12.7. Әгәр мөрәҗәгатьтә карар дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә вазыйфаи зат компетенциясенә керми торган мәсьәләләр булса, гражданга кая һәм нинди тәртиптә мөрәҗәгать итәргә кирәк дигән аңлатма бирелә.

**13. Дәүләт хакимияте органнары ягыннан**
**муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту тәртибе**

13.1. Оешманың лицензиядә каралган таләпләрне һәм шартларны

үтәвен контрольдә тоту планлы һәм планнан тыш тикшерүләр үткәрү юлы белән тиешле лицензияне биргән лицензияләүче орган тарафыннан үткәрелә.

13.2. Лицензияне туктатып тору яки гамәлдән чыгару гамәлдәге законнар нигезендә тормышка ашырыла.

13.3. Татарстан Республикасы муниципаль берәмлек җирле үзидарә органнары тарафыннан муниципаль хезмәт күрсәтүне контрольдә тоту Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының «Фактта күрсәтелә торган хезмәтләрнең сыйфатының билгеләнгән стандартларга туры килүен бәяләү тәртибе турында»гы карары нигезендә гамәлгә ашырыла.

**14. Түләүле яки бушлай муниципаль хезмәт күрсәтү**

Муниципаль хезмәт бушлай күрсәтелә.

---